**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 июль № 524

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәт урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 4 нче май, 170 нче номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 декабрь, 954 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәт урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.7 пунктка, 3.1 пунктның икенче абзацына, 3.2 пунктка, 3.4 пунктка «, җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 май, 194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрь, 1196 нчы, 2014 ел, 20 май, 334 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның бишенче абзацына «, җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан

оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган 2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацына «, җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның җиденче абзацына һәм 14 пунктның җиденче абзацына «(Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 218 нче карары белән расланган 2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

15 пунктның тугызынчы абзацына «мөһер белән беркетә» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2015 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән махсус) җиһазландыру (җайлаштыру), инвалидларның, шул исәптән кресло-коляскадан файдалана торган инвалидларның, эш урыннарына тоткарлыксыз керә алуы өчен кирәкле инфраструктура булдыру чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 795 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 март, 196 нчы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган 2014 – 2015 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

20 пунктның икенче абзацына «(Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\524.docx